## Сәләтле бала - мәктәп горурлыгы

Гимназия - Бердәм дәүләт имтиханында районда югары 200 балл җыючы укучылары булуы белән дә данлыклы.

2022 ел - Шамил Баянов химия һәм биология фәннәре буенча бердәм дәүләт имтиханнарыннан йөзәр балл җыйды. Хәзер Санкт-Петербург дәүләт медицина университетының икенче курс студенты.

2023 ел – Лиана Исмагилова химия һәм биология фәннәре буенча бердәм дәүләт имтиханнарыннан йөзәр балл җыйды. Казан дәүләт медицина университетының беренче курсында белем ала.

**Шамил Баянов:**

Укытучыны хөрмәт итсәң, аның укыткан фәне дә якын була. Безнең гимназия укытучылары - таләпчәнлек, аерым бер үҗәтлек белән, фанатларча бирелеп эшләүче укытучылар алар. Үзләрен яраттырып, укыткан фәннәренә мәхәббәт уяткан укытучыларыбызга тирән хөрмәтемне белдерәм.

Математика – фәннәр патшасы, диләр. Математиканы, минемчә, укып кына өйрәнеп булмый. Математиканы белү өчен логика кирәк. Кагыйдәләр белмәсәң, эш алгоритмын өйрәнмәсәң, математикада бернинди алга китеш тә булмаячак. Без моны бөтен йөрәгебез белән аңлыйбыз, фән нигезләрен тырышып үзләштерәбез.

Тарих, география, җәмгыять белеме дәресләре -тормыш итү өчен, күзаллавыбызны үстерү өчен бик кирәкле фәннәр.

Минем иң яратып өйрәгән фән – рус теле, инглиз теле. Чит телне аралашу дәрәҗәсендә беләсем килә. Инглиз телен барлык укучы да мәктәптә үк камил белергә тиеш дип саныйм.

Барлык фәннәрдән дә кирәклерәк фән – физкультура, минемчә. Бала вакыттан ук физик тәрбия, спорт белән шөгыльләнү, актив тормыш алып бару – озын гомер итүнең төп шарты. Сәламәтлекләрен югалткач кына “эх” диючеләр шактый, кызганычка каршы. Мин кечкенәдән спортны үз иттем. Җиңел атлетика, футбол, хоккей – минеке! ГТО буенча да күрсәткечләрем яхшы. Килчәгемне спорт белән бәйләмәсәм дә, сәламәтлек өчен спорт белән шөгыльләнүне туктатмаячакмын.

**Лиана Исмагилова:**

Нииндидер фәнне үзгәртергә кирәк дип тапмыйм. Укытучыларга төпле белем биргәннәре өчен бик зур рәхмәт! Иң яраткан укытучым Рәмилә Сабирзяновна Гуссамова. Ул сабыр, мәрхәмәтле, тырыш, укучыларны аңлый һәм тырышлыкны күрә белә. Кирәк вакытта таләпчән дә була. Дәреснең бер генә минутын да әрәм итми. Химияне өйрәнгәндә дә математика дәресендә алган белемнәрнең файдасы зур булды.

Укырга барлык дәресләргә дә әзерләнеп, аңламаганнарымны видеодан өйрәнеп йөрдем. “2” ле алсам да хурлыкка санамаган булыр идем. Ул миңа тагын да тырышып укырга этәргеч бирер иде.